Татарстан Республикасы Нурлат шәһәре 13нче номерлы “Талым” балалар бакчасы мәктәпкәчә белем бирү муниципиаль бюджет учреждениясе

**Проектның темасы:**
**“Габдулла Тукай әсәрләре буйлап сәяхәт”**

Төзүче: тәрбияче Шәйхетдинова Гөлия Наил кызы

2011 ел

Габдулла Тукай – бөек татар шагыйре. Ул- безнең күгебезне яктыртыр өчен чыккан һәм батмас кояшыбыз. Иҗатының зур өлешен поэзия били. Шуңа күрә, икенче төрле, аны татар поэзиясенең кояшы, дип атарга була.

2011 елның 26 апрелендә бөек шагыйребезнең тууына 125 ел тулды.

Ул күп иҗади мирас калдырган. Аның шигъри, әкияти иҗатына балаларның, тәрбиячеләрнең һәм үземнең күпсанлы кызыксынуларым " Габдулла Тукай әсәрләре буйлап сәяхәт" темасына проект эшләргә этәрде.

**Максат:** Габдулла Тукай иҗаты белән танышып, аның әсәрләре аша балаларга телебезнең матур, татлы, аһәңле, моңлы икәнлеген аңлату. Туган телебезнең рухи байлыгыбыз хәзинәсенә ачкыч булуын төшендерү.

**Проектның үзенчәлеге**: күпкырлы белем һәм тәрбия бирү

**Актуальлеге:** Габдулла Тукай әсәрләрендә туган җиргә, аның табигатенә, кешеләренә тирән мәхәббәт сугарылган. Аның шигырьләре, әкиятләре ничәмә буын балаларга туган илен, телен, хезмәтне яратырга, сабыр булырга өндәп тәрбия бирә. Әсәрләр аша бала әйләнә-тирә дөньяны танырга, татар халкының гореф-гадәтләрен, өлкәннәрне хөрмәт итәргә, игелекле, мәрхәмәтле, миһербанлы һәм тыйнак булырга өйрәнә.

**Бурычлар:**

1.Татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукайның тормыш юлы һәм иҗаты белән таныштыру.

2. Шагыйрь иҗатына карата кызыксыну уяту, мәхәббәт тәрбияләү, аның иҗаты турында күбрәк белү теләге үстерү.

3. Г. Тукай шигырьләренең һәм әкиятләренең образлы телен аңларга һәм тоярга өйрәтү.

4. Шигырь, җыр-бию, әкиятләр аша туган телебезнең байлыгын, матурлыгын күрсәтү, аңа сак караш тәрбияләү һәм соклану хисләре уяту, гореф-гадәтләребезгә, милләтебезгә хөрмәт белән карарга һәм ихтирамлы булырга өйрәтү.

5. Татар балалар әдәбияты буенча эти-әниләрнең күзаллауларын киңәйтү һәм әдәби әсәрне гаилә белән укырга кирәклегенә өндәү.

**Поектта катнашучылар:** балалар, тәрбиячеләр, ата - аналар

**Проектның үтәлү вакыты һәм этаплары:**

**1.** Әзерләнү этабы

1.1. Матур әдәбият әсәрләрен уку, өйрәнү

1.2. Перспектив план һәм балалар, тәрбиячеләр, эти-әниләр белән эшләү графикларын төзү

**2.** Төп этап

2.1. Проектны гамәлгә ашыру өстендә эшләү, шөгыль конспектлары язу, методик әсбаплар җыю

2.2. Әти-әниләрне, тәрбиячеләрне, балаларны эшкә җәлеп итү

**Методлар:**

1. Күзәтү
2. Эзләнү
3. Сәяхәт (экскурсия)
4. Театраль эшчәнлек
5. Анкеталаштыру
6. Уен- дәресләр

**Көтелгән нәтиҗә:**

1. Балалар бакчасында, төркемдә, гаиләдә, китапханәдә балаларны Г. Тукай әсәрләре белән таныштыру буенча кирәкле шартлар тудыру.
2. Балаларның күзәтүчәнлекләрен, иҗади мөмкинлекләрен, танып- белү активлыкларын, коммуникатив күнекмәләрен үстерү.
3. Балаларны Г. Тукай әсәрләре белән таныштыру буенча эш системасы барлыкка китерү.
4. 80% эти-әниләр проект үтәлешендә актив катнашыр дип көтелә.
5. 25% балаларның үз идея һәм җөмләләрен әйтә белү осталыкларына ирешү.
6. Ата-аналар тарафыннан гаилә белән китаплар укырга кирәклеген аңлау.

**Проектның идеясе :** бүгенге көндә, балаларга нәрсә укырга, дигән сорау актуаль булып тора. Балаларның уку өлкәсе дөрес формалашкан булырга тиеш. Чын мәгънәсендә Габдулла Тукайның колач җитмәслек дәрәҗәдә күп иҗади мирасы аша, аның сихри, әкияти әсәрләрен укып, бу сорауга җавап таба алырбыз.

**Проектның әһәмияте:**

Г. Тукайның шигырьләр һәм әкиятләр дөньясын өйрәнгәндә бала үз алдына, Нәрсә эшләсәм ярый? Нәрсә эшләргә ярамый? Ничегрәк үзеңне тотарга? кебек сораулар куя һәм аларны чишәргә тырыша. Шулардан чыгып, үзенә, эшләгән эшенә нәтиҗә ясый. Бер-берсе белән аралашып, яхшыны яманнан аерырга өйрәнә. Шагыйрь иҗатын өйрәнгәндә китапханә, гаилә белән күмәк хезмәттәшлек итүнең яңа юнәлеше барлыкка килде. Мәктәпкәчә белем бирү оешмасының алар белән күмәк эшләү нәтиҗәсендә, бер-берсенә йогынты ясаулары артты.

**Эшләнгән эшләр:**

1. Перспектив план
2. Тема буенча методик материал
3. Шөгыль конспектлары
4. Әти - әниләр өчен чаралар
5. Презентация
6. Балалар белән күңел ачу чаралары
7. Диагностика
8. Яңа уеннар белән танышу
9 Китапханәгә, музейга сәяхәт

**Библиография**


1. К. В. Закирова, Р. А. Борһанова. “Балалар бакчасында тәрбия һәм белем бирү”. К., “ Мәгариф”, 2009
2. К. В. Закирова, Р. Ә Кадырова. “Гаиләдә һәм балалар бакчасында әхлак тәрбиясе”. К, “ Мәгариф” , 1999.

3. Ф. М. Зиннурова. “ Үз илемдә, үз телемдә”. К., “ Мәгариф”, 2009.
4. Р. К. Шәехова, К. В. Закирова. “ Иҗат баскычлары”, К., “ Школа”, 2001.Р. Ягүфәров. “ Кәҗә- мәкәрҗә”. К, “ Мәгариф”, 1994.
5. К. В. Закирова “Күңел ачыйк бергәләп”. Бәйрәм иртәсе сценарийлары. К., 2003.
6. К. В. Закирова “ Уйный- уйный үсәбез”, К, “ Мәгариф”,2005
7. М. Ф. Кашапова “ Иң татлы тел- туган тел”. К., “ Мәгариф”, 2004.
8. Г. Тукай “ Шүрәле”. К, Тат. Кит. Нәшр., 2009.
9. Г. Тукай. “ Кәҗә белән сарык” әкияте. К., Тат. Кит. Нәшр., 2001.
10. Г. Тукай. Сайланма әсәрләр. К., Тат. Кит. Нәшр., 2010.
11. Г. Тукай. Әкиятләр. К., 2011.
12. Г. Тукай. Сайланма әсәрләр. Дүрт томда. Том 1. Таткнигоиздат, Матур әдәбият редакциясе, 1955